


CE
Made in Norway
© L. A. Larsen AS, NO-4401, www.larsen.no

Егерме дүртенче декабрь.
Аваз ияртемнәре.

Аваз ияртемнәренең мөстәкыйль сүзме, әллә ярдәмче сүз төркемеме булуын билгеләү юлы:

- Соравын ачыклау;
- Нинди сүз төркемен ачыклавын билгеләү;
- Нинди җөмлә кисәге булуын билгеләү.

2 19 нчы күнегү.

1.Тимергә-тимер бәрелеп “чык” иткәч, Мәүләви җиңел сулап куйды.

**Чык иткәч- соравы *ничек?*, фигыльне ачыклый, җөмләдә хәл.**

2.“Һау!” да “Һау”
Бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән,кирегә йөгерә.

**“Һау!” да “Һау” өрә- соравы *ничек?*, фигыльне ачыклый, җөмләдә хәл.**

3. Агач яфракларына тып-тып итеп эре тамчылар тамды.

**Тып-тып итеп тамды- соравы *ничек?*, фигыльне ачыклый, җөмләдә хәл.**

4.Кара каргалар, “Карр... карр...” дип, каты шауладылар.

**“Карр... карр...” дип шауладылар- соравы *ничек?*, фигыльне ачыклый, җөмләдә хәл.**

**Ш.Галиев “Рус казлары -га-га-га...”**

Русларда да бар казлар
Татарда да бар казлар.
Рус казлары: га-га-га, ди,
Татар казы: кыйгак-кыйгак, ди.

Русларда да үрдәк бар,
Татарда да үрдәк бар.
Руснык ылар: кря, кря, ди,
Татарныкы: бак, бак, ди.

Русларда да бар әтәч,
Татарда да бар әтәч.
Русларның: кукареку!
Татарның: кикерикүк!

Русларда да бар маэмай,
Татарда да бар маэмай.
Рустагысы: гав, гав, ди,
Татардагы: һау, һау, ди.

Дөрес җавап:

8




**Су буенда бакалар**
**Бак-бак диләр дә, баталар,**
**Бак-бак диләр дә, калкалар.**
**Уңга да бөгеләләр,**
**Сулга да бөгеләләр,**
**Артка да бөгеләләр,**
**Алга да бөгеләләр**
**Һәм суга сикерәләр.**

Бакчада умарта кортлары безелди.
Күл буенда бакалар бакылдый.
Кетәклектә тавык кытаклый.
Өйдәге тынлыкны бозып, сәгать кенә текелди.
Безелди- без-без
Бакылдый- бак-бак
Кытаклый- кыт-кыт
Текелди- тек-тек

Торрыйк-торрыйк = торналар
Гөр-гөр = күгәрчен
Кыйгак- кыйгак = каз
Кикерикүк = әтәч
Карр-карр = карга
Күк-кү- күк-кү = күке
Бак-бак = үрдәк
Бип- бип = каз бәпкәсе
Чут-чут= сандугач
Тук-тук= тукран
Кыт-кыт= тавык
Чик-чирик =чыпчык

